РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№ 141**

«2018-2020 елларга Кукмара муниципаль
районында сәламәтлек саклау системасын
үстерү» муниципаль программасына
үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 20 декабрендәге 820 номерлы карары белән расланган «2018-2020 елларга Кукмара муниципаль районында сәламәтлек саклау системасын үстерү» муниципаль программасын әлеге карарның кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең 10.02.2020
елның 141 номерлы
карарына кушымта

# «2018-2020 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУНЫ ҮСТЕРҮ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

## Программа паспорты

(алга таба – Программа)

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында сәламәтлек саклауны үстерү» муниципаль программасы |
| Программаның муниципаль заказчысы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитет, Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Роспотребнадзор идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарында территориаль бүлеге |
| Программаның төп башкаручылары | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты<br>- Башкарма комитет, Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Роспотребнадзор идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарында территориаль бүлеге<br>- «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Татарстан Республикасы Саба, Кукмара, Мамадыш районнарында филиалы<br>- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Кукмара районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе<br>- ГАУЗ «Кукмара үзәк район хастаханәсе»<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Кукмара район дәүләт ветеринария берләшмәсе<br>«Хезмәт даны» газетасы редакциясе – «Татмедиа» ААҖ филиалы<br>-Җирлек башлыклары |
| Программаның максатлары | - Авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру<br>-Халыкның йогышлы куркынычсызлыгын тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | - Йогышлы авырулар барлыкка килүдән һәм таралудан халыкны яклау чараларын тормышка ашыру<br>- Халыкның санитар культурасы дәрәҗәсен күтәрү<br>- Йогышлы авырулар барлыкка килүгә һәм таралуга ярдәм |

| | |
|---|---|
| | итә торган сәбәпләрне бетерүгә юнәлдерелгән дәүләт чараларын үткәрү; |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | Муниципаль программа бер этапта тормышка ашырыла. Тормышка ашыру вакыты 01.01.2018 – 31.12.2020 еллар |
| Программаны финанс белән тәэмин итү | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме<br>2332,1 мең сум, шул исәптән еллар буенча:<br><br>2018 – 749,9 мең сум<br>2019 – 779,0 мең сум<br>2020 – 803,2 мең сум<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Йогышлы авырулар һәм алар аркасында үлүчеләр санының кимүе |

## РАЗДЕЛ 1. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ ӨЛКӘСЕНЕҢ АГЫМДАГЫ ТОРЫШЫ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

Кукмара муниципаль районы территориясендә 2016 елда йогышлы авыруның 2770 очрагы теркәлгән, шул исәптән 2230 ОРВИ. ГАУЗ «Кукмара РҮХ»еннән һәм башка дәвалау-профилактика учреждениеләреннән «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Татарстан Республикасы Саба, Кукмара, Мамадыш районнарында филиалы бүлегенә йогышлы авыруны теркәү турында ашыгыч хәбәр килгәндә, йогышлы агентны тапшыру механизмын һәм юлларын өзү һәм эпидемия процессын үстерүне туктату өчен, авырулардан (йөртүчеләрдән) йогышлы авырулар китереп чыгаручы вируслар, бактерияләр бүленеп чыгып, авырулар (носительләр) белән контактка ия булган тышкы мохит объектлары аша да таралуын кисәтү максатларында «Йогышлы һәм паразитар авыруларны профилактикалау буенча гомуми таләпләр» 3.1/3.2.3146-13 СП нигезендә, ашыгыч хәбәр кергәннән соң 12-24 сәгать эчендә дезинфекция, дератизация, дезинсекция һәм санитария-эпидемияләргә каршы чаралар үткәрелә.

Кирәк булганда, йомшак инвентарьны камера белән эшкәртү үткәрелә, инвентарь йогышлы чыганаклардан «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Татарстан Республикасы Саба, Кукмара, Мамадыш районнарында филиалы базасында урнашкан стационар электр дезинфекция камерасына автомобиль транспортында китерелә, эшкәрткәннән соң, адрес буенча кире илтеп бирелә. 2016 елда Кукмара районы территориясендә йогышлы авыруларны эшкәртү тиешле барлык инфекция учакларында дезинфекция, дератизация, дезинсекция һәм санитария-эпидемияләргә каршы чаралар вакытында үткәрелде.

Йогышлы авырулар учакларында йомгаклау дезинфекциясен уздырудан тыш, йортларда да, шулай ук оештырылган коллективларда да инфекция чыганагын ачыклау, тапшыру юлларын ачыклау, бетерү һәм алга таба таралуны булдырмау максаты белән бактериологик һәм санитар-химик анализларга пробалар алу (эпидемиягә каршы санитар чаралар) үткәрелә.

Талпанга каршы эшкәртү Кукмара муниципаль районы территориясендә талпан вирусы энцефалиты, талпан боррелиозы кебек йогышлы авыруларны булдырмау максаты белән «Талпан вируслы энцефалитын профилактикалау» СП 3.1.3.2352-08 нигезендә үткәрелә.

Талпанга каршы эшкәртү кешеләр күпләп йөри торган урыннарда, урман-парк зоналары, урман массивлары, «Сабантуй» милли бәйрәмен үткәрү урыннарында талпанга каршы эшкәртү тиешле мәйдан күләмен билгеләгәннән соң үткәрелә. Эшкәртүне үткәргәннән соң, 3-5 көннән дә соңга калмыйча, талпанга каршы (акарицид) эшкәртүләрнең нәтиҗәлелегенә контроль үткәрелә.

2016 елда талпанга каршы чаралар район территориясендә 170212,77 кв. м мәйданда 80000,0 сумлык үткәрелде.

Маляриягә каршы чаралар «Россия Федерациясе территориясендә паразитар авыруларны профилактикалау» СанПиН 3.2.3215-14 нигезендә үткәрелә.

Профилактик дезинсекция (эпидемиягә каршы) чаралар, энтомологик мониторинг нәтиҗәләрен исәпкә алып, кан суыручы бөҗәкләр санын киметү максатларында, шул исәптән трансмиссив авырулар чыганакларын формалаштыру урыннарында (торак пунктлар янындагы сулыклар һәм рекреацион зона һ.б.) үткәрелә.

Кукмара муниципаль районы территориясендә малярия черкиләре барлыкка килергә мөмкин булган 10 сулык (үсемлеклекләр белән капланган) исәпкә алынды. Бу сулыкларны тикшерү җәйге чорда һәр 7-10 көн саен үткәрелә. Сулыкларда малярия черкиләре личинкаларын ачыклаганда, бу сулыкны маляриягә каршы эшкәртү үткәрелә. 2016 елда малярия черкиләре личинкалары белән зарарланган 10 га сулык ачыкланган. Маляриягә каршы эшкәртү 30000, 00 сумга 10348,27 кв. м мәйданда башкарылган.

Кукмара районы ГЛПС (Геморрагическая лихорадка с почечным синдромом - бөер синдромлы геморрагик бизгәк) эпидемия учагы буенча авырулар санының югары дәрәҗәсе булган районнарга карый. 2.7.8 п. нигезендә «Бөер синдромлы геморрагик бизгәкне профилактикалау» СП 3.1.7.2614-10 бөер синдромлы геморрагик бизгәк территориясенең эпидемик активлыгы авырулар санының дәрәҗәсе белән билгеләнә:

югары – 100 мең кешегә 10,0 һәм аннан да күбрәк

уртача – 100 мең кешегә 1,0 дән 9,0 кадәр

түбән – 100 мең кешегә 1,0 дән кимрәк;

2016 елда муниципаль районда ГЛПС белән авыруның 5 очрагы теркәлгән, 100 мең кешегә күрсәткеч – 9,6 (2015 елда – 9 очрак , 100 мең кешегә күрсәткеч – 17). Эпидемиягә каршы чараларга 2016 елда 689,5 мең сум акча бүлеп бирелгән, шул исәптән 399,5 мең сум – тоташ һәм барьерлы дератизациягә. Татарстан Республикасы бюджетыннан (субвенцияләрдән) акча хисабына тоташ һәм барьерлы дератизацияләнергә тиешле авыл җирлекләре территорияләренә төзәтмәләр кертелде. Үткәрелгән дератизация эшләре 221,9 га гомуми мәйданда 15 эпидемиологик яктан әһәмиятле авыл җирлегендә каралган һәм үткәрелгән. 2016 елда барьерлы һәм тоташ дератизациягә субвенцияләр тулысынча үзләштерелгән.

Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр, шәхси эшмәкәрләр белән ел саен йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәш буенча объектларга хезмәт күрсәтү буенча шартнамәләр төзелә, анда ай саен дератизация, дезинсекция эшләрен үткәрү чагылдырыла. Эпидемиологик яктан әһәмиятле объектларда ай саен дератизация, дезинсекция, дезинфекция чаралары үткәрелә. Яз һәм көз айларында кимерүчеләр санын исәпкә алу үткәрелә.

Бөер синдромлы геморрагик бизгәге булуда шикләнелүче авыру ГАУЗ «Кукмара РҮХ»енә мөрәҗәгать иткәндә, эпидемиолгик анамнез җыела, аннары «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Татарстан Республикасы Саба, Кукмара, Мамадыш районнарында филиалы бүлегенә ашыгыч хәбәр җибәрелә, авырудан алынган материаллар диагнозны раслау яки кире кагу өчен Казан шәһәренең вирусология лабораториясенә җибәрелә.

Районда ел саен торак пунктларны һәм алар янәшәсендәге территорияләрне санитар чистарту айлыгы үткәрелә. Район халкы арасында бөер синдромлы геморрагик бизгәк йоктыруның килеп чыгуын кисәтү һәм таралуын кисәтү максатыннан, СПЭК карары белән җирлек башлыкларына апрель-май айларында ачык территорияләрне республика бюджетыннан бүлеп бирелә торган субвенцияләр күләмендә генә түгел, ә куркыныч территорияләренең өстәмә мәйданын эшкәртү өчен өстәмә финанс чаралары бүлеп бирүне дә күздә тотып, язгы профилактик эшкәртү оештырырга тәкъдим ителде. Шулай ук оештыру-

хокукый формасына бәйсез рәвештә, Хезмәт һәм оешма җитәкчеләренә объектларда, шул исәптән урман массивы янында урнашкан территорияләрдә дә кимерүчеләргә каршы профилактик дератизация эшкәртүләрен тәэмин итәргә тәкъдим ителде.

Район җирлекләре башлыклары тарафыннан авыл җирлекләре территориясендә рөхсәт ителмәгән чүплекләр барлыкка килүгә юл куймау буенча даими эш алып барыла, аеруча эпидемиологик әһәмияткә ия булган объектларда кимерүчеләргә каршы профилактик дератизацион эшкәртүләр үткәрелә. Муниципаль район башкарма комитеты тарафыннан җирлек территориясендә рөхсәт ителмәгән чүплекләрне ачыклау фактына даими тикшерүләр үткәрелә.

«Экосервис» ҖЧҖ халыкның каты көнкүреш калдыкларын даими чыгарып тора, каты көнкүреш калдыклары полигонында кимерүчеләргә каршы профилактик дератизацион эшкәртүләр үткәрә.

Кукмара урманчылыгы тарафыннан халык еш йөри торган урман кишәрлекләрен, урман территорияләрен җил һәм давылларда егылган агачлардан санитар чистарту эшләре алып барыла.

Ел саен зарарлану куркынычы булган предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә ГЛПС профилактикасы буенча «риск төркеме» контингентлары өчен укулар үткәрелә. 2016 елда 2216 кеше белем алырга тиеш иде, чынлыкта 2216 кеше белем алды. Халык белән Бөер синдромлы геморрагик бизгәкне профилактикалау буенча санитар-агарту эше үткәрелде: лекцияләр – 4, әңгәмәләр – 150, 800 белешмәлек һәм листовкалар әзерләнде, һәм «Хезмәт даны» район газетасында «Бөер синдромлы геморрагик бизгәге – авыр йогышлы авыру» дигән мәкалә бастырылды.

ГЛПС профилактикасы мәсьәләләре СПЭК утырышларында һәм белем бирү оешмалары, авыл хуҗалыгы предприятиеләре, предприятиеләр җитәкчеләре һәм коммерция структуралары оешмалары җитәкчеләре киңәшмәләрендә каралды.

## II. Программаның төп максатлары, бурычлары. Программаның көтелгән ахыргы нәтиҗәләрен тасвирлау, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Программаны тормышка ашыруның максаты – авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, шул исәптән Кукмара муниципаль районы территориясендә йогышлы авырулар, малярия, талпан энцефалиты, талпан боррелиозы кебек йогышлы авырулар таралуны профилактикалау, кисәтү һәм булдырмау һәм ГЛПС, ОКИ, вируслы гетатит һ.б. кебек тиз тарала торган авыруларны булдырмау.

Программаның бурычлары:

- Йогышлы авырулар барлыкка килүдән һәм таралудан халыкны яклау чараларын тормышка ашыру.

- Халыкның санитар культурасы дәрәҗәсен күтәрү.

- Йогышлы авырулар барлыкка килүгә һәм таралуга китерүче сәбәпләрне бетерүгә юнәлдерелгән дәүләт чараларын үткәрү.

Программаның мәсьәләләрен хәл итү өчен, ГЛПС белән авыручылар санын киметүгә юнәлдерелгән түбәндәге чараларны тормышка ашыру каралган:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- салам, печәнне кырлардан һәм урман массивларыннан алып чыгып пресслау эшләрен тулы күләмдә алып барырга;

- биогаз технологияләрен кулланып, терлекчелек калдыкларын утильләштерүнең нәтиҗәле системасын үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру;

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларда ике тапкыр тоташ дератизация, ашлык складларында, элеваторларда, тегермәннәрдә, терлек сую пунктларында, икенчел чимал складларында ай саен дератизация үткәрү;

- авыл хуҗалыгы эшләрендә мәшгуль затларны шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең Кукмара район дәүләт ветеринария берләшмәсенә түбәндәгеләрне үткәрергә:

-авыл хуҗалыгы предприятиеләре объектларында (терлекчелек, кошчылык һәм башкалар) дератизация чаралары уздыру;

- авыл хуҗалыгы предприятиеләре объектларында ветеринария-санитария чаралары үткәрү;

-авыл хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан үткәрелә торган дератизация чараларының нәтиҗәлелегенә дәүләт ветеринария күзәтчелеген оештыруны оештыру.

3. ГАУЗ «Кукморская ЦРБ»ка тәэмин итәргә:

- ГЛПС, малярия, талпан энцефалиты, талпан боррелиозы клиник күренешләре белән авыручыларны һәм, йогышлы авыру булуга шикләнгән затлар медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать иткәндә, эпидемиология анамнезын җыюга аерым игътибар юнәлтеп, вакытында ачыклауны;

- медицина оешмаларын авыруларны дәвалау өчен кирәкле дару препаратлары белән;

- ГЛПС, малярия, талпан энцефалиты, талпан боррелиозы һ. б. булуга шикле барлык авыруларны мәҗбүри лаборатор тикшерү;

- «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Татарстан Республикасы Саба, Кукмара, Мамадыш районнарында филиалы базасындагы Кукмара бүлегенә ашыгыч

хәбәрләр тапшыру белән йогышлы авыруларның барлык очракларын теркәү һәм исәпкә алу;
- йогышлы авыруларны профилактикалау буенча халык белән санитар-агарту эшен уздыру.
4. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының территориаль урман хуҗалыкларына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:
- торак пунктларга (бигрәк тә халык күп йөри торган), гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек яки дача коммерцияле булмаган берләшмәләренә, сәламәтләндерү оешмаларына янәшә торган урман территорияләрен көнкүреш чүп-чардан, ауган агачлардан системалы рәвештә чистартуны үткәрү;
- кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе территориаль органнарыннан алынган чистартылырга тиешле урман территорияләре турында мәгълүматны эштә куллану;
-Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Төньяк территориаль идарәсенең махсуслашкан инспекциясе белән берлектә урманнардан файдаланучыларның бөтенесенең дә территорияләрне санитар чистарту буенча чараларны үтәвен контрольдә тоту;
-урман хуҗалыгы эшләрендә мәшгуль затларны шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү;
- урман хуҗалыгы эшләрендә мәшгуль затлар арасында йогышлы авыруларны профилактикалау буенча мәҗбүри инструктаж оештыру .
5. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә, муниципаль район оешмалары, муниципаль районның торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләре белән берлектә, каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм эшкәртү системасын чүп-чарны сортларга аеру линияләрен камилләштерү, каты көнкүреш калдыкларын полигоннарда күмү күләмнәрен киметү исәбенә камилләштерү буенча эшне дәвам итәргә.
6. Кукмара муниципаль районы административ комиссиясенә Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Төньяк территориаль идарәсенең махсус инспекциясе белән берлектә көнкүреш калдыкларының рөхсәт ителмәгән (санкцияләнмәгән) чүплекләрен бетерүгә юнәлдерелгән, гаепле затларны административ җаваплылыкка тартуны да кертеп, чаралар күрергә.

7. «Татмедиа» ААҖ филиалы – «Хезмәт даны» газетасы редакциясе – йогышлы авыруларны профилактикалау мәсьәләләре буенча халыкка мәгълүмат җиткерүдә ярдәм күрсәтергә
8. Җирлек башлыкларына:

- халыкның күпләп ял итү урыннарында, йогышлы авыруларның табигый учакларында кимерүчеләрне юк итү чараларын системалы рәвештә уздыруны тәэмин итәргә;
-торак пунктлар чигендә урман территорияләрен көнкүреш калдыкларыннан, ауган агачлардан системалы рәвештә чистартуны тәэмин итәргә;
- торак пунктлардагы тузган корылмаларны, рөхсәт ителмәгән чүплекләрне бетерергә, каты көнкүреш калдыклары полигоннарын санитар закон таләпләренә туры китерү буенча чаралар күрергә;
- Татарстан Республикасы бюджетыннан аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән профилактик дератизация, дезинсекцион чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;
-өстәмә финанс чаралары бүлеп бирүне һәм аларны ГЛПС табигый учакларында, урман массивларына һәм көнкүреш калдыклары полигоннарына янәшә торган торак пунктларда тоташ һәм барьерлы дератизация эшкәртүләрен башкаруга максатчан файдалануны күздә тотарга;
- гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре җитәкчеләре белән, Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарында территориаль бүлеге вәкилләре дә чакырып, участокларны язгы һәм көзге эшкәртү мәсьәре буенча ел саен киңәшмәләр оештырырга һәм үткәрергә;

9. Предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:
- кимерүчеләр үтеп керү һәм яшәү өчен шартларны юк итү максатларында биналарда, корылмаларда санитар-техник чаралар үткәрү;
- оешмалар территорияләрен һәм якын-тирә территорияләрне төзекләндерү;
- биналарда һәм корылмаларда (шул исәптән эпидемиологик әһәмияткә ия булган объектларда, һәр ай саен) тычкансыман кимерүчеләргә каршы дератизацион чаралар оештыру һәм үткәрү;
- балanstагы объектлар янындагы чистартылган территорияләрдә тычкансыман кимерүчеләргә каршы каршы көзен һәм язын профилактик дератизация чараары үткәрү;

9. «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Саба, Кукмара, Мамадыш районнарында филиалына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:
- Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр хисабына башкарыла торган дератизация, дезинсекция эшкәртүләренең нәтиҗәлелегенә контрольлек итәргә;
- аккредитацияләнгән белем бирү оешмалары базасында хезмәткәрләрнең һөнәри укыту һәм квалификацияләрен күтәрү;

- белешмәлек һәм листовкалар таратып, халык арасында йогышлы авыруларны профилактикалау буенча киң санитар пропаганда.

10. Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Роспотребнадзор идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарында территориаль бүлегенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:
- җирле радио һәм «Хезмәт даны» газетасын, басма материалларны кулланып, йогышлы авыруларны профилактикалау мәсьәләләре буенча халыкка мәгълүмат бирү буенча чаралар үткәрергә;
- Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, зоогеографик куркынычларны исәпкә алып, тоташ һәм барьерлы дератизацияләнергә тиешле территорияләрне планлаштырырга, шул исәптән гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциячел булмаган берләшмәләренә якын булган урманнарны көзге барьерлы дератизацияләүне эшкәртү планына кертү,
-Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән тоташ һәм барьерлы дератизацияләнергә тиешле территорияләр турында мәгълүматны кызыксынган органнарга һәм оешмаларга (җирлекләргә, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының территориаль урман хуҗалыкларына, «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Саба, Кукмара, Мамадыш районнарында филиалына) җибәрергә;
-ачык территорияләрдә вакытында профилактик дератизация, дезинфекция эшкәртүен оештыруга, үткәрүгә һәм аның сыйфатына контроль ясау;
11. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына дератизация, дезинфекция эшкәртүгә муниципаль контракт төзегәндә, хезмәт күрсәтүчеләрдә махсус җиһазлар, әзерлекле персонал булу, дератизация чараларын саклау һәм куллану шартларын үтәү, лицензия булуны исәпкә алырга кирәк.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме
2332,1 мең сум, шул исәптән еллар буенча:

2018 – 749,9 мең сум
2019 – 779,0 мең сум
2020 – 803,2 мең сум

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## IV. Программаны тормышка ашыру механизмы һәм нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыруны планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм гомуми контрольдә тотуны ел саен максатчан күрсәткечләрне һәм программа чараларына чыгымнарны, программаны тормышка ашыру механизмын һәм башкаручыларның составын аныклый, чараларны үтәү өчен җаваплы кешеләрдән программа үтәлеше турында мәгълүматлар соратып ала торган Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Санитар-эпидемияләргә каршы комиссия, Кукмара районында Экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссия башкара.

Программаны тормышка ашыру Программа чаралары исемлеге, бюджет ассигнованиеләре, шулай ук чыгымнар турындагы мәгълүмат булган еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча программаның нәтиҗәлелеген бәяләү

- 2020 елга Кукмара районы бөер синдромлы геморрагик бизгәкнең эпидемия учагы буенча авырулар санына уртача дәрәҗәдә булган район булырга тиеш - 100 мең кешегә 1,0 дән 9,0 гә кадәр.
- Кукмара муниципаль районы территориясендә йогышлы авыруларның таралуына юл куймау (малярия, талпан энцефалиты, талпан боррелиозы һәм ГЛПС, ОКИ, вирус гепатиты һ. б. кебек тиз таралучан авыруларга юл куймау).